**«Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы**

*(«Алабуга» махсус икътисади зонасының административ бинасы)*

**ПЛЕНАР УТЫРЫШ**

**30.11.2017** **Алабуга шәһәре**

**Васил Шәйхразиев:** Хәерле көн, хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич! Хәерле көн мөхтәрәм утырышта катнашучылар, газиз милләттәшләр, хөрмәтле кунаклар! Сезне барыгызны да Татарстан җирендә, Алабуга җирендә тәбриклибез. рөхсәт итсәгез, үзебезнең форумны башлап җибәрербез.

Хөрмәтле коллегалар, бүген безнең Россия Федерациясенең 36 төбәгеннән һәм 13 чит илдән эре бизнес вәкилләре катнаша. Иң мөһиме ел саен, менә 12нче тапкыр очрашабыз. Быел тагын безнең арабызда безнең Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич монда. Әйдәгез барыбыз да алкышлап алыйк, рәхмәтле булыйк.

Без утырышыбызны башлап җибәрәбез. Әле яңа гына выставка карадык. Шуңа күрә хәзер чыгыш ясаулар булачак. Кемнәр чыгыш ясый, регламент буенча 5-7 минутка сыерга тырышыгыз. Чөнки безнең күбегезне тыңлыйсы килә.

Хөрмәтле дуслар, коллегалар! Бүгенге форум кысаларында татар эшмәкәрләренең 3 юнәлештә алып барган эшчәнлегенә тукталырбыз.

1. Кытай Халык Республикасының Шэньчжэнь шәһәрендә урнашкан халыкара сәүдә мәйданында «Татар йорты» ачылуы һәм аның кысаларында эшмәкәрләребезнең эшчәнлеге турында.
2. Татарстан Президенты фәрманы нигезендә эшләнгән халыкара «Татар-тур» проекты концепциясен тормышка ашыру юнәлешләрен билгеләү.
3. Татар эшмәкәрләренең Татарстан Республикасы икътисады белән элемтәләрен урнаштыру мәсьәләләре каралыр.

Әгәр дә, Рөстәм Нургалиевич, рөхсәт итсәгез, без чыгышларны башлар идек. Беренче сүз «Алабуга» махсус икътисади зонасының генераль директоры урынбасары, Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы, икътисад фәннәре кандидаты **Таҗетдинов Илдар Рәшит** улына бирелә. Рәхим итегез!

**Илдар Таҗетдинов:** Хәерле көн, хөрмәтле Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич, хөрмәтле кунакларыбыз һәм хезмәттәшләребез! Без бик шатбыз "Алабуга" махсус икътисади зонасы исеменнән Рәсәйнең иң зур, уңышлы махсус икътисади зонасында сәламнәргә. Татарстанның эшлекле хезмәттәшләрен үзебездә кабул итү – безнең өчен бик зур дәрәҗә. Әлеге очрашу сезгә яңа эшлекле элемтәләр урнаштырырга, Республиканың элемтәләрен киңәйтүгә һәм аның икътисадын ныгытуга ярдәм итәчәк дип ышанып калабыз. Рөхсәт итегез махсус икътисади зонасы турында сөйләп китәргә һәм презентацияне тәкъдим итәргә.

Безнең зона резидентлары арасында әйдәп баручы дөнья һәм шулай ук чит ил брендлары бар. Без актив рәвештә халыкара эшчәнлек алып барабыз, Россия күләмендә һәм башка илләрдә инвесторлар эзлибез. Шуңа күрә бүген Татарстан партнерларына "Алабуга"ның мөмкинлекләрен тәкъдир итү безнең өчен зур дәрәҗә.

"Алабуга" махсус икътисади зонасы Мәскәүдән 1000 чакрым ераклыкта, Яр Чаллы һәм Алабуга шәһәрләреннән ерак түгел, Кама индустриаль кластерының үзәгендә урнашкан. Өч ел рәттән Татарстан Республикасы инвестицион яктан җәлеп итү рейтингында Россия Федерациясендә иң яхшы регион булып санала. "Алабуга"ның өстенлеге булып, Россиянең иң эре сәнәгать үзәкләренең берсендә урнашуы, югары үсеш алган сәнәгать инфраструктурасы, шулай ук салым һәм таможня ташламалары санала. "Алабуга" махсус икътисади зонасы резидентлары җир, милек һәм транспорт салымнарын түләүдән 10 елга азат ителәләр.

Табышка салым 5 ел буена беренче табыш алган көннән башлап, 2% ка кадәр киметелгән, ә алдагы 5 елда куйган акча (ставка) 7% тәшкил итә.

Киләчәктә, 2055 елга хәтле - махсус икътисади зона режимының эшчәнлеге тәмамлануга - резидентлар өчен табышка салым ставкасы 15,5% тәшкил итә. Чагыштыру өчен – Россиядә табышка салым 20% тәшкил итә.

“Алабуга”да ирекле таможня зонасы режимы эшли. Махсус икътисади зонасы территориясенә чит илләрдән жиһазлар кертү вакытында өстәмә кыйммәткә салым һәм читтән кертү таможня пошлинасы салынмый. Иң мөһим таләп - жиһазлар махсус икътисади зонасыннан чыгарга тиеш түгел, югыйсә жиһазларның иясе читтән кертү таможня пошлинасын һәм өстәмә кыйммәткә салымны түләргә тиеш була.

«Алабуга”ның төп өстенлеге – дөньякүләм дәрәҗәдәге сәнәгать инфраструктурасы. Махсус икътисади зонасының 11 ел эшләү дәверендә дәүләт аңа 30 млрдка якын акча кертте. Бүгенге көндә 20 км$^2$ мәйданда эре җитештерү төзелеше өчен барлык шартлар да тудырылган – автомобиль һәм тимер юллар бар, электр, газ, суүткәргеч  кертелгән.

“Алабуга”да инфраструктурага тоташу бушлай. Чагыштырып карасак, куәтлелекнең (мощность) мегаваттын тоташтыру Мәскәүдә 30 млнга якын тора,  Татарстанда  - 6 млн., ә “Алабуга”да  тоташтыру бушлай.  Аренда бәясе һәм җир участокларын түләп алу хакы “Алабуга”да шулай ук символик рәвештә. Төзелеш вакытында инвестор җирнең 1 гектарын 30 мең түләп арендаласа, завод төзелеп беткәч, аның 1 гектар җирне 100 мең бәясенә сатып алырга мөмкинлеге булачак.

Шулай ук “Алабуга” махсус икътисади зонасында теге яки бу сәбәпләр аркасында үзенең шәхси бинасын төзергә әзер булмаучы компанияләр өчен әзер җитештерү мәйданнарын арендалау мөмкинлеге бар.  Бу безнең модуль тибындагы “Синергия” индустриаль паркы. Ул 20 модульдән тора һәм аның гомуми мәйдәны 25 мең квадрат метр тәшкил итә. Әлеге слайдта “Синергия”ның бер модуле эчке яктан тәкъдим ителгән.

“Алабуга” махсус икътисади зонасында барлык таможня эшләрен башкарыр өчен шартлар тудырылган. Әлеге шарт импортерлар һәм

экспортерлар өчен бик мөһим. Безнең бу бинада урнашкан таможня посты Россиядә иң яхшы постларның берсе булып санала, әлеге бәя федераль таможня хезмәте тарафыннан бирелде.

"Алабуга"га җайлы гына барып җитү мөмкинлеге бар. Һәр конне махсус икътисади зонасыннан 45 минут ераклыкта урнашкан "Бегишево" аэропортыннан Мәскәүгә һәм кирегә 6 рейс башкарыла, ә очу вакыты исә нибары 1,5 (сәгать ярым)ны тәшкил итә.

"Алабуга" махсус икътисади зонасы инвесторларының күрше шәһәрләр - Яр Чаллы, Алабуга, Түбән Каманың хезмәт ресурсларына керү мөмкинлеге бар. Мәскәү яисә Петербург белән чагыштырганда, уртача хезмәт хакы югары түгел һәм бу инвесторлар өчен өстенлек булып тора.

Ел саен Кама кластерының уку йотлары безнең махсус икътисади зонасы резидентлары ихтыяҗлары өчен 800гә якын белгеч әзерлиләр. "Алабуга" махсус икътисади зонасының уңышлы урнашуы Россиядә һәм чит илләрдә яхшы сату базарын гарантияли. Эре диңгез транспорт җирләренә йөкләрне тимер юл һәм елга транспорты аша җиткереп була.

"Алабуга" махсус икътисади зонасы халыкара абруйлы рейтингларда күзәтелә. fDiintelligence журналы һәм Financial Times төркем нәшрияте һәр ел күзәтелеп бара торган иң яхшы махсус икътисади зоналары арасында 3нче тапкыр эре резидентлар арасында "Алабуга"ны Ауропада яхшы икътисади зонасы итеп билгеләде.

Әлеге сызымда сез бүгенге көндәге махсус икътисади зона резидентларының урнашуын күрә аласыз, барлыгы территориядә 22 эшләп килүче завод урнашкан. "Алабуга" махсус икътисади зонасы резидентлары арасында әйдәп баручы дөньякүләм брендлар бар. Безнең иң бай резидентларның берсе булып, «Форд Соллерс» компаниясе тора. «Алабуга» заводында Ford Kuga, Transit, Explorer машиналары һәм җиңел машиналар өчен йөрткечләр (двигатели) җитештерелә.

Француз компаниясе Air Liquide - техник газлар җитештерү өлкәсендә дөньяда лидер булып тора. “Алабуга” заводында алар чынында исә “һавадан” акча эшлиләр: һаваны алалар һәм аны тәшкил итүче газларга бүләләр: азот һәм кислород. Бу энергияне күп сыйдырышлы җитештерү булып санала, шуңа күрә компания өчен челтәргә тоташу бушлай булуы бик мөһим иде.

Бөтен дөньяда билгеле булган җылылык үткәрми торган материаллар җитештерүче компания Rockwool “Алабуга”да ташлы мамык (каменная вата) җитештерү буенча үзенең заводын төзеде. «Прайсс-Даймлер Татнефть» компаниясе - Татарстанның “Татнефьт” һәм “Прайс-Даймлер” Германия компаниясенең уртак оешмасы. Алабугадагы оешма пыялалы сүс (стекловолокно) чыгара.

“Полиматиз” - «Нижнекамскнефтехим»ның бүлендек оешмасы. Ул тукылмаган сүс (волокно) һәм аның нигезендә җитештерелгән продукция чыгара. Мәсәлән, медицина халатлары һәм баш киемнәре.

Германиянең «Сария» компаниясе “Алабуга”да терлекчелекнең калдыкларын эшкәртү буенча завод төзеде. Мөгез һәм төяклардан ахыр чиктә сөяк оны (костная мука) һәм хайван мае килеп чыга.

“Алабуга”ның эре инвесторларының берсе булып Төркия тора. Бүген аның 6 заводы бар. Аларның иң зурысы “Кастамону» компаниясе оешмасы. Әлеге зур агач эшкәртү комбинаты МДФ-панельләр һәм идән ламинаты җитештерә. «Кастамону» компаниясе кебек төрек холдингына керүче, «Хаят Кимья» заводы «Алабуга»да Papia һәм Familia брендлары астында бәдрәф кәгазъләре чыгара.

«Тракья Гласс Рус» заводы - «Шишеджам» төрек холдингының һәм «Сен Гобен» француз компаниясенең уртак оешмасы. Әлеге заводта “яфраклы” пыяла җитештерелә, мәсәлән “Мәскәү Сити” бинасы шул пыялалар белән эшләнгән.

«Шишеджам» холдингының «Алабуга»да булган тагын бер заводы - «Аутомотив Глас Альянс Рус» дип атала. Әлеге завод Россиядә җитештерелүче чит ил автомобильләре өчен пыялалар чыгара.

Углеродлы җепселләр (волокно) булдыручы "Росатом" заводына караган «Алабуга» җепселләр заводы Алабуганың югары технологияле оешмаларының берсе булып тора. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк. Бүгенге көндә махсус икътисади зонасында «Росатом»ның икенче заводы проектлаштырыла. Әлеге завод бу оешма өчен чимал җитештерәчәк, димәк "Алабуга"да стратегик чималның локальләштерү өлеше үсә бара.

Россиядә билгеле булган «Интерскол» электрокораллар җитештерүче компаниясе үзенең барлык продукциясен диярлек безнең махсус икътисади зонасында чыгара.

"RMA" Германия компаниясенең заводы "Газпром" ихтыяҗлары өчен торба арматурасын чыгара.

"Armstrong" Америка компаниясе "Алабуга" махсус икътисади зонасында Россиядәге үзенең беренче түшәм панельләрен җитештерү заводын төзеде. Әлеге панельләрне без хәстаханәләрдә яки офисларда күрә алабыз.

Безнең тагын бер төрек резидентыбыз «Джошкуноз» компаниясе. Ул «Форд Соллерс» компонентлары өчен тәэмин итүче булып тора, алар машиналарга кузов детальләрен мөһерлиләр (штамповать). Бүгенге көндә аның янында тагын бер җитештерү үзәге төзелә. Әлеге завод мөһерләү өчен корыч прокат әзерләячәк.

Бар дөньяга танылган "3М" компаниясе "Алабуга"ны үзләренең Россиядәге икенче заводын төзү урыны итеп сайлаганнар. Бүген алар бездә торбаүткәргеч өчен антикоррозик каплау әзерлиләр.

"Алабуга"да шулай ук азык-төлек җитештерү дә бар. Мәсәлән, "Белая Дача" компаниясенең заводы. Ул "Макдоналдс" компаниясен яшелчәләр һәм салатлар белән төп тәэмин итүче булып тора. Сез "Алабуга"ның "Белая Дача" продукциясен гади кибетләрдә күрә аласыз.

“Белая Дача” янында «Хави Логистик» логиситика үзәге урнашкан. Ул “Макдоналдс” компаниясенең логистик операторы булып тора. Әлеге склад “Алабуга”дан 1000км радиуста урнашкан рестораннарны продукция белән тәэмин итә. Шулай ук «Макдоналдс»ның тагын бер тәэмин итүчесе - “Алабуга”да эшләгән «Хухтамаки» финнар заводы – ул бер тапкыр гына куллана торган кәгазь стаканнар җитештерә.

Менә бу полиэтилен торба җитештерүче “Дизайн Рус” төрек компаниясе. Ул «Синергия» индустриаль паркында урнашкан.

Бер атнадан ачырга планлаштырылган Россия компаниясенең яңа заводы «Барс Технолоджи». Ул машиналар өчен аккумуляторлар чыгарачак.

Бельгиянең «Драйлок Текнолоджиз» компаниясе агымдагы елны “Алабуга”да балалар һәм өлкән кешеләр өчен санитар-гигиена продукциясен чыгару буенча оешма төзеде.

Бүгенге көндә “Алабуга”да 56 резидент-компаниясе рәсмиләштерелгән. Резидентларыбыздан 111 миллиард сум инвестицияләр салынган. Махсус икътисади зонасының үсеш стратегиясе 2023нче елга әлеге санның 120гә кадәр артуын, инвестицияләрнең тулы күләме 360 млрд сум тәшкил итүен һәм заводта 16 мең кеше хезмәт итүен күздә тота.

Презентациянең ахырында “Алабуга”ның мөһим бер конкурентлы өстенлеген әйтәсеп үтәсем килә. Без бик яхшы аңлыйбыз, инвесторларны бизнес өчен уңайлы шартлар булдырып кына түгел, ә уңайлы яшәү шартлары тудырып җәлеп итәргә кирәк. Шуның өчен махсус икътисади зонадан ерак түгел, без Алабуга шәһәре янында халыкара мәктәп һәм заманча коттедж поселыгы төзедек. Халыкара мәктәптә укыту чит ил стандартлары буенча инглиз телендә алып барыла. Мәктәп янәшәсендә 40 йорттан торган Европа дәрәҗәсендәге коттедж поселыгы урнашкан. Алар резидентлар компаниясенең топ-менеджерларына арендага бирелә.

Татарстанда эре бизнес өчен генә түгел, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлеккә дә шартлар тудырылган. Уңайлы эшмәкәрлек климаты, төбәк җитәкчелеге ягыннан ярдәм итү – без сезне боларның барсы белән дә файдаланырга һәм үзегезнең проектларыгызны бездә, муниципаль районнарыбызда, безнең республикада гамәлгә ашырырга чакырам.

Шуның белән минем кыскача презентациям тәгәлләнде. “Алабуга”да сезгә ошар дип ышанып калам. Уңышлы эшләр сезгә!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Илдар әфәнде. Чыннан да, без быел үзебезнең программаны караганда, күп кенә эшмәкәрләр монда килеп карыйсы дигәннәр иде. Кичә очрашкан вакытта без сөйләштек. Беренчедән, без монда килеп, шушы булган тәкъдимнәрне карап, үзебезнең арада яки безнең компаньоннар арасында монда инвесторлар таба алабыз. Икенчесе, монда эшли торган производстволар булгач, алар чимал сатып алалар яки аларның үзләренең әзер продукцияләре бар. Алай да болай да монда ташырга яки сатырга алырга була. Өченчедән, монда безнең иң зур яхшы культурада төзелгән производстволар. Без аның турында кичә сөйләштек.

Монда һәрбер завод яңа технология, соңгы сүз белән эшләнгән станоклар, энергоэффективность, килеп-карап, үзебезнең көндәлек тормышыбызда куллана алабыз. Һәм иң мөһиме – бу Рәсәй күләмендә “Алабуга” махсус икътисадый зонасы. Иң эффективный, иң эшли торган, беренче урынны алган зона. Бу безнең горурлыгыбыз. Һәрбер килгән монда инвестор безнең Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич аша монда эшкә урнашкан һәм аның гарантиясе белән эшли. Шуңа күрә монда эш тә бара, шартлар да уңайлы. Хактан да, бу бик матур презентация. Без әйттек инде, безнең сайт бар, материаллар бар, ул раздаткаларда бар. Аларны алып, бүген, иртәгә, берсе көнгә уйлап бетереп, Аллабирса, тагын берничә тапкыр бу сорауларга әйләнеп кайтырбыз.

Хәзер сүз Кытайдан килгән милләттәшебез, Кытай Халык Республикасының Шэньчжэнь шәһәрендә урнашкан «Татар йорты» генераль директоры, ШОС эшлекле Советының вәкаләтле вәкиле, Даван Шоппинг

Шэньчжэнь сәүдә компаниясенең генераль директоры **Галиев Әхмәтҗан Торсынтай** улына бирелә. Рәхим итегез!

**Әхмәтҗан Галиев:** Әссәләмәгәләйкүм, хөрмәтле Президентыбыз, Рөстәм Нургали улы, дөньяның төрле почмакларыннан килгән газиз милләттәшләр! Сезгә Кытай татарларныннан кайнар сәламнәр алып килдек. Әлеге форумда чыгыш ясарга мөмкинлек бирүегез өчен бик зур рәхмәт!

Мин яшьтән милләтебезнең рухын аңлап үскән бала. Безгә яшьтән аңлаттылар, бабаларыбызның иң изге җирләре Татарстан икәнен. шуңа күрә Казанга килгәнче үк, Татарстан, Казан турында белә идек. Казанга килү безнең өчен бик көтелмәгән вакыйга булды. Бәхет булды дип әйтер идем. Дөньяларның шулай үзгәрүен күп еллар элек читтән, ерактан карап, Татарстанны, Казаныбызны белән идек. Монда килеп, бу чараларны күргәннән соң, татарларыбызның бердәм икәнлегенә, татарларыбыз һәрвакыт бер-берсе белән тату һәм бердәм булып яшәвенә бик каты сокландык.

Мин үз чыгышымда Кытай Халык Республикасының Көнъяк регионында урнашкан Шэньчжэнь шәһәрендә күптән түгел генә ачылган «Татар йорты» сәүдә үзәге турныда сөйләп үтәсе килә. Ата-бабаларыбыз безгә тарихта мәңге истә калырлык исемнәр, эзләр калдырып киткәннәр. Аларның берсе “Бөек Ефәк юлы”. Без хәзер шушы юлдагы эзләр буйлап, араларыбызны якынайтырга, бергә хезмәттәшлек итү юлларын эзләргә тиеш. Моны мин безнең өстәге бурыч дип саныйм.

Шэньчжэнь шәһәре Кытай Халык Республикасының көнъяк территориясендә, дөньяга атаклы Гонконг каласы янәшәсендә урнашкан иң зур сәүдә үзәге. Ул иң зур заманча шәһәр булып санала. Биредә 30 миллионга якын кеше яши. Төнъяк вокзалдан 20 минутлык, диңгез кырыенда урнашкан 7 данә калаларга бик якын урнашкан. Һава юлы, диңгез, поезд һәм транспорт юлларын берләштерә торган үзәк. 110 км радиус эчендә 110 миллионнан артык кеше яши.

Соңгы елларда Кытай Халык Республикасының импорт ашамлыклар проектын дәүләт дәрәҗәсендә күтәрелүе аркасында халыкара күргәзмә, сәүдә

үзәге эшли башлады. Проектны гамәлгә ашыруда 460 миллион Америка доллары кертелгән. Бу зур комплекс Кытайда бердәнбер иң зур үзәк булып санала. Бу бер елда 365 көн ялсыз эшли торган зур комплекс.

Ул 5 функциональ бүлекне тәшкил итә. Аның беренчесе – сәүдә күргәзмә үзәге. Икенчесе – элитлы урам, өченчесе аның төп офис, дүртенчесе – халыкара сатып алу үзәге, бишечесе – бизнес-класс дәрәҗәле кунакханәләр. Логистика үзәге сатучы складыннан соң сатып алучы складына кадәр булган операцияләрне эшләргә уңайлык тудыра. Дистрибьютерлар аркылы эшләү һәм таможня хезмәткәрләренең булушуы операцияне тагын да тизләтә.

Импорт эшләнмәләрен тикшерү лабораториясе дә бар. Даими рәвештә белгечләрне яңа сату системаларына өйрәтеп торалар. Моннан тыш продукциянең һәм хезмәт күрсәтүләрнең төп төрләре булган авыл хуҗалыгы һәм ашамлык продуктлары, туризм, спорт, ял итү, инвестицияләр һәм халыкара интеграция. Болар барысы да комплекслы эшләнә.

Продуктлар импортлау буенча Халыкара үзәк Кытай сәүдә челтәрләренә турыдан туры чыгу, 250 меңнән артык Кытай һәм Гонконг күпләп сату һәм ваклап сату кибетләре, уникаль Шэньчжэнь финанс икътисадый гигополисы аша арадашчыларсыз һәм югалтуларсыз диярлек эшли.

Безнең Шэньчжэнь халыкара компаниябез Шэньчжэнь халыкара күргәзмә үзәгендә “Татар йорты”н оештырды. Аның мәйданы 500 кв м. Биредә Татарстан һәм Россиянең 10га якын экспортлау вәкилләре эшли. “Татар йорты” рәсми үзәге эшли башлавына бүген нәкъ 1 ай. Шуңа да карамастан, якында 4 контейнер ашамлыклар Кытайга озатылу алдында тора. Татар йорты сәүдә үзәге бер дәүләт корпорациясен Татарстанга инвестицияләү һәм төзү формасында үз проектларын куярга әзер.

Төрле бөртекле культуралар сатып алу буенча сөйләшүләр алып барабыз. “Татар йорты” сәүдә үзәгебез фәкать ризык кына түгел, ә башка өлкәдәге эшләнмәләрне дә Кытай базарына сата ала. Татарстаныбыз һәм Россия регионнары дөнянең төрле почмакларындагы милләттәшләребез

белән Кытай Халык Республикасы арасында элемтәләрне тагын да ныгытырга күпкырлы мәйданчык ролен башкара ала дип ышанам.

Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Кытай Халык Республикасына эш сәфәре кысаларында халыкара ашамлыклар күргәзмә сәүдә үзәгендә безнең “Татар йорты”нда булды. Һәм хезмәтләребезгә бәя биреп, мондыйрак сүзләр әйтте. Кытай белән хезмәттәшлегебезнең практик нәтиҗәләреннән берсе үзәк белән багланышлар булу күркәм күренеш. Бу брендлар өчен күргәзмә павильоны гына түгел, ә сәүдә итү, инвестицияләр җәлеп итү урыны. Бизнес өчен уңайлы платформа булган яңа үзәкнең эшенә без сокландык.

Быел сентябрь аенда шушы компания идарәсе делегациясе Татарстан Республикасында булды. Бүген монда “Татар йорты” павильоны эшли. Без Татарстан продукциясен Кытай базарына тәкъдим итү мөмкинлегенә бик шатбыз. Ышанам, әлеге партнерлык Кытай Халык Республикасында үз товарларыбыз базарын киңәйтү, Россиядә үз товарларын һәм продуктларны уртак җитештерүче белән кызыксынучы Кытай инвесторларын җәлеп итүгә ярдәм итәчәк.

Мөхтәрәм Рөстәм Нургали улы,  сезгә чиксез рәхмәтләребезне әйтәсебез килә. Халкыбыз нинди җирдә генә яшәсә дә, барысына да кыска вакыт эчендә булышырга һәрвакыт әзер торасыз. Ходай сезгә саулык-сәламәтлек насыйп итсен.

Милләтебез Бөек Ефәк юлында бик югары нәтиҗәләргә ирешкән. Кытай Халык Республикасы рәисебез Си Цзиньпин әфәнде уртага куйган Бөек Ефәк юлында “Один пояс – один путь” инвестициясе инициативасы безгә бүгенге заманда яңадан бөек эзләр калдырырга мөмкинлек бирә. Татар халкы – булдыра торган халык. Кайда гына яшәсә дә тырыш, эшчән, барлык милләттләр арасында алдынгы рәтләрдә торып эш итәләр. Уртак ният һәм максат була икән, без тагын да булдырачакбыз. Халкыбызның башкарып яткан эшләре шактый күп. Мондый манзараларны күреп, ничек татар булуың белән горурланмыйсың?

Кадерле милләттәшләр! Без эшлисе уртак эшләр, сөйләшәсе уртак сүзләр бик күп. Аларны тормышка ашыру өчен безгә бердәм булып эш итәргә кирәк. Сүземнең азагында барыгызга да саулык-сәламәтлек, эшләрегездә зур алгарышлар, уңышлар телим. Бер-беребезне һәрвакыт яклыйк. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Әхмәтҗан әфәнде! Хәзер сүз «Карпайские семечки» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять җитәкчесе **Баймашев Касыйм Әмин** улына бирелә. Рәхим итегез!

**Касыйм Баймашев:** Исәннәрмесез, кардәшләр, милләттәшләр! Кадерле Рөстәм Нургалиевич! Беренчедән, зур рәхмәтләремне белдерәсем килә бүген җыелышны оештыручыларга, Бөтендөнья татар конгрессы комитеты рәисе Ринат Зиннуровичка һәм Милли Шура рәисе Васил Гаязовичка.

Мин Мордовия Республикасында тудым, үстем, Белозерье авылында. Мин көнбагыш белән шөгыльләнәм. Бүгенге выставкада күбегез күрде безнең бизнесны. Мин бу бизнеска 2002 елда тотындым. Әйтәсем килә, бу бизнес – гаилә бизнесы. Бу бизнеста эш кылалар бөтен Баймашевлар. Эшли башлагач, без бик тырыштык сыйфатлы продукция булдырырга, сыйфатлы эшләргә. Күп көчләр куйдык, күп тырыштык. Бүгенге көндә, әлхәмдүлилләх.

2000-2010 елларда мин бик күп сәфәр кылдым Европа рынокларына. Анда сәфәр кылгач. Миңа Аллаһы Тәгалә күзне ачты. Бүгенге көндә Европа базарында 2010 елдан тотынып, елдан-ел минем объем производства 25% күтәрелә барды. Бүгенге көндә без Европа базарына машиналар белән санасак, отгружаем 6 евро фура, тоннага әйләндерсәк, то аена 100 тонна көнбагыш озатабыз Европа базарына. Европа базарында кайда булсагыз да, безнең продукцияне таба аласыз -“Карпайские” или “На крылечке”.

Бүген без 3 продукциябезне Германиягә, Франциягә, Италиягә, Испаниягә, Англиягә, Грециягә, Португалиягә, Чехословакиягә поставляем. Инде икенче ел Израиль иле белән эшлибез. Без больше всего продукциябезне, 65% Европага чыгарабыз. Монда бүген күп кешеләр безнең

продукцияне күрделәр. Бик зур теләгем бар бу бизнеста үзебезнең татарлар белән эшләргә. Кемнең теләге бар, безнең сайтыбыз бар, анда керегез.

Бүгенге көндә мин зур рәхмәтләремне әйтәсем килә. Без көз көне Үрүмчидә выставкада булдык. Икенче выставкада мин эләктем Әхмәтҗан белән. Ул әйтте инде Международный центр импортной продукции турында. Без анда урын алдык, продукцияне выставили. Мин шулай ук телим Китайский рынокка чыгарга. Запас мощности безнең производствода бар. Күп итеп Китайга да, Россиягә дә обеспечить итә алабыз, Иншааллаһ. Бик зур рәхмәт тыңлаганыгыз өчен!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Касыйм әфәнде! Выставка вакытында безнең президентыбыз Рөстәм Нургалиевич безгә карарлар бирде. Менә монда минем коллега Альберт әфәнде утыра монда. Шуңа күрә без бүгенге очрашудан соң протокол язып, шушы сезнең көнбагышларны сату буенча республика күләмендә берничә тәкъдимнәр ясарбыз. Бик зур рәхмәт сезгә!

Хәзер сүз **Хисмәтуллин Раил Габдулхак** улына бирәсем килә. Ул безнең Пермь краеннан “Тенториум” компаниясе Президенты. Рәхим итегез!

**Раил Хисмәтуллин**: Рәхмәт! Татарча сөйләргә авыррак миңа, шуңа гафу итегез, русча сөйлим.

Хочу поблагодарить также Президента Республики Татарстан и всех организаторов этих мероприятий. Конечно, это очень взаимообогащающие форумы, в которых мы находим новых друзей, партнеров и решения по бизнесу. Мы по-хорошему завидуем, что есть такие замечательные зоны, как «Алабуга» - зона особого экономического развития. Здесь, конечно, хотелось бы работать. Это то, что нужно бизнесу сегодня.

В своей сфере мы работаем уже около 30 лет. Компанию «Тенториум», кстати, в шутку называют «Тенториум» созвучно с «Татариум». То что у нас работают много сотрудников татар. Вся верхушка, естественно, татарская. Думаю, что предыдущие ораторы также это объяснили. Народ у нас

работящий, умеет по-настоящему отдаться делу. Это шутливое название мы много десятилетий уже несем.

«Тенториум» - это группа предприятий, в состав которого входит 2 завода, курорт с водо-грязелечением. Пчелоужаления людей применяется. Это, наверное, редкое явление, круглый год у нас вместо иголок, которые ставят в рефлексные зоны по китайской методике, мы используем пчелоужаление. Больно, но очень эффективно.

Мы также имеем племенной репродуктор пчел темно-лесной породы и развивающийся агрокомплекс, где есть птицеферма. Мы специализируемся на перепелках. Молочное стадо коз, заготовка и переработка дикорастущих трав, кореньев, ягод, орехов, грибов и т.д. Нужно сказать, что один из наших заводов, которому исполнилось только 5 лет, является самым современным в мире в своей теме, поскольку мы перерабатываем не мед, как медофасующее предприятие, а производим глубокую переработку всех известных продуктов пчеловодства. В том числе таких редких, как пчелиный яд, пыльца, которую мы за 5 лет переработали порядка 740 тонн. Это много, потому что сырье редкое. Порядка 80 тонн перги, в том числе мы перерабатываем и такие редкие продукты, как хитозан или пчелозан. Это тот продукт, который мы предложили рынку в 2001 году, впервые его представив на конгрессе в ЮАР. Получается он из подмора пчел, которые естественным образом образуется в зимний период, т.е. в корпусе пчел.

Мы компания, которая выпускает на сегодня более 130 наименований продукций для здоровья, порядка 90 продуктов для питания. И сейчас мы более глубоко осваиваем изготовление косметической продукции, более медицинского направления. За время этой работы наш завод вместе с немецкими инженерами спроектировали, он построен был немецкой фирмой. Мы с гордостью можем говорить о том, что сегодня в своей отрасли, в своей теме мы являемся единственным заводом полностью соответствующим всем мировым нормам по стандартам качества, безопасности продукции для человека.

Поэтому мы осуществляем также работу в плане международном, все более выходя на европейский рынок. Также работаем и с Азией. Когда мы проходили сейчас экскурсию, слышали, что работают с Китаем по плитам, которые здесь изготавливаются. Мы тоже можем сказать о том, что Китай у нас сегодня покупает мед, что тоже само по себе редко.

Нам пришлось, конечно, непросто. За последнее время, особенно с потерей в определенной мере рынка Украины, которая составляла 30%, осталось около 3%, тем не менее, мы уверенно сегодня идем в рост. Мы уверены в том, что эта продукция будет востребована везде. В настоящий момент работают у нас около 600 человек. А в сервисном центре, которые у нас по принципу дистрибуции работают, они в России составляют примерно 700 центров, а в Татарстане работают 35 таких точек.

Активными потребителями, которые зарегистрированы в нашем интернет-магазине, который у нас еще молодой, мы в мае его только открыли, у нас уже зарегистрированы по Республике Татарстан около 6 тысяч жителей Республики.

Девиз компании – качество и честность. Продукты компании постоянно отмечаются знаками «Сто лучших товаров России». На международной выставке в конгрессе «Апимондия», мы постоянные участники, в этом году порадовало то, что в Стамбуле участники были широко представлены и от Башкирии, Татарии. Представители Татарии и Башкирии получили 10 медалей. Компания «Тенториум» получила 3 золотых, 1 бронзовую и 1 серебряную медаль.

Впервые почти за 30 лет мы получили золото за мед. Мед дягилевый. Нужно сказать, что это самая престижная для «Апимондии» награда, потому что мы участвовали в конкурсе среди 450 образцов меда со всего мира. Вот такие результаты. Нужно сказать, что целевая составляющая серьезная. Радует то, что как раз традиционным для татаро-башкирского населения является медовый промысел. Всем это известно. Его, конечно, хотелось бы

всячески поддерживать, потому что где же еще здоровья-то взять. Здоровье – это все, в общем-то.

Мы за последние эти 5 лет провели большое исследование, которое было на базе Ханты-Мансийского колледжа олимпийского резерва. Эта работа была в составе комплексной научной группы, с Московским институтом Пирогова, с Томским медицинским университетом и с нашей лабораторией, которая привела к тому, что мы за эти 3 года, во-первых, провели огромное количество тестирований, до 20 тысяч анализов провели. В последующие 2 года провели работу дальше в Москве.

Мы запатентовали способ применения продукции для здоровья, который по своему значению, по действию близок к мельдонию, который всем нам известен. Т.е. это защита от кардиоваскулярного риска. Нашей сотрудницей была защищена диссертация, Хисматуллиной Ириной. У нас был получен патент. Мы для медицинских вузов получили методическое пособие, которое было утверждено Минздравом России.

Это большой прорыв. Это состоявшееся государственное частное партнерство, которое мы мечтали развить, может быть, в республике. Т.к. следующий год, наверное, у нас верстается, в планах. Мы вот немножко переговорили. Может быть, где-нибудь в апреле провести в Казани большую конференцию, именно по теме «Здоровая нация» и этой теме дать хорошее ускорение. Потому что есть что показать, есть и кому рассказать, есть кого привлечь. Эта тема могла бы стать также очень серьезным прорывом, которого в настоящее время каждый ждет, потому что страшно смотреть, что мы видим по телевизору, к фармации. К этому всему мы очень осторожно относимся.

Компания большое внимание уделяет благотворительной деятельности. У нас работают люди разных национальностей, вероисповеданий в том числе. Поэтому мы с уважением относимся ко всем конфессиям. Мы построили мечеть в Башкортостане, в Артауле, это родина моего отца. Участвовали в строительстве Соборной мечети в Москве. Мы уже более 15

лет ведем работу детским центром. Делаем все для того, чтобы маленьким пациентам было получше.

Также хочется поделиться с вами тем, что мы впервые в этом году участвовали на международной выставке «Медиа» в Москве с мультфильмом, который называется «Пчелография». Это образовательный мультфильм, который рассказывает детям о географии, поэтому пчелография называется, о географии как таковой и о пчелином царстве. Сейчас в свободном доступе 12 серий.

Спасибо большое, коллеги! Всем желаю всего наилучшего. Еще раз благодарю всех организаторов. Для нас честь здесь присутствовать.

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт! Ә хәзер сүз Мәскәү шәһәре «Папирус – Столица» сәүдә йортының генераль директоры **Мөслимов Ильяз Булат** улына бирелә. Рәхим итегез!

**Ильяз Мөслимов:** Добрый день, уважаемый Рустам Нургалиевич, уважаемые участники форума «Деловые партнеры Татарстана»! Во-первых, тоже также хочу поблагодарить вас, уважаемый Президент, Исполком Всемирного конгресса, организаторов за возможность побывать и увидеть работы ОЭЗ «Алабуга». Воистину, лучше один раз увидеть, чем сто раз услышать. Увиденные масштабы инвестиции меня, например, очень сильно впечатлили.

Я представляю компанию «Папирус-Столица». Я учредитель компании. Компания работает более 26 лет на рынке поставок бумаги для полиграфических предприятий издательства России и стран СНГ. Также у нас есть поставки в Италию и Германию небольшие. Хотя компания не столь большая, всего 150 человек в управлении, но мы ведем на рынке Российской Федерации в 13 регионах России, а также в Республике Крым имеются свои представительства и склады.

В прошлом году мы открыли на базе в Казахстане государственное предприятие, которое возглавляет Светлана Назарбаева, филиал и также активно стали работать на этом восточном рынке. За это время построены

собственные логистические центры и склады в Московской области, в городе Санкт-Петербург и в центре юга страны – в городе Ростове-на-Дону. Оборот компании за прошлый год составил свыше 7 миллиардов рублей. По планам инвестиций на ближайшие годы стоит завершение 2 и 3го очереди логистического центра в Ростове-на-Дону, строительство в Московской области фабрики бумаг с общим объемом инвестиций 1,5 миллиарда рублей на территории 72 гектар.

«Папирус» также всегда принимал и принимает участие в благотворительных акциях полпредства Республики Татарстан в Москве и Всемирного конгресса татар. Вы знаете, уважаемый Президент, наше участие в создании самой большой книги в мире, Коран – хранится в Булгарах. Относительно увиденного сегодня, уважаемый Рустам Нургалиевич, мне было бы интересно изучить возможность зайти в «Алабугу». Спасибо!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт! Ә хәзер сүз Кырым Республикасы «Ларешес» тарихи музей-тыюлыгы директоры **Альтин Гөлләвер Рөстәм** улына бирелә. Рәхим итегез!

**Гөлләвер Альтин:** Әссәләмәгәләйкүм, хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич, кадерле дуслар! Я хотел бы сегодня кратко рассказать о проекте, над которым мы начали работать. Это международный туристический маршрут “Татар-тур”. Если вы помните, на прошлом заседании “Деловые партнеры Татарстана” была представлена идея. Позже была разработана стратегия реализации этого проекта, которое должно показать целостное представление нашего историко-культурного наследия, наших связей. Дело в том, что татары расселены на территории многих регионов. И это не просто так. У каждого есть своя историческая родина. Этот проект помог бы реализовать и показать наши национальные обычаи, традиции и многое другое.

Согласно поручению Президента, чуть позже мы разработали эту стратегию. Мы стали ориентироваться на 400 миллионов туристов во всей Евразии. Т.е. это общий объем въездного туризма. Нужно, конечно, эту цифру взять на вооружение. Разбили на 11 направлений и по одному из них

начали прорабатывать. Понятно, что проект содержит различные виды туризма. У нас просто нет времени все это рассказывать.

